МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

01.03.2022

___________

Казан шәһәре

**БОЕРЫК**

34-ОД

№___________

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы халкының сәүдә объектлары мәйданы белән иң аз дәрәҗәдә тәэмин ителеш нормативларын раслау турында» 2016 елның 7 октябрендәге 259-ОД санлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 3 июнендәге 1049-р санлы күрсәтмәсе белән расланган 2021-2025 елларга Татарстан Республикасында күчмә сәүдә объектларын кулланып, басма продукция тарату системасын үстерү һәм аңа ярдәм итү буенча чаралар планының («юл картасы») 1 пунктын үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы халкының сәүдә объектлары мәйданы белән иң аз дәрәҗәдә тәэмин ителеш нормативларын раслау турында» 2016 елның 7 октябрендәге 259-ОД санлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «А.Ш.Хөсәеновка» сүзләрен «Г.Я.Лернерга» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы халкының сәүдә павильоннары һәм киосклар белән тәэмин ителү нормативы» таблицасының «Татарстан Республикасы халкының күчмә сәүдә объектлары мәйданы белән иң аз күләмдә тәэмин ителү нормативы (10000 кешегә сәүдә объектлары саны)» юлында «1,5» саннарын «1,4» саннарына алмаштырырга.

2. Җыелма бүлек җитәкчесенә (Л.М. Кадыйровага) Боерыкны рәсми басылып чыкканнан соң Министрлык сайтында урнаштырырга.

3. Юридик бүлек җитәкчесенә (Р.Р.Гыйльфановага) Боерыкны, дәүләт

теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары –
министр А.Ә. Кәримов